


# ***Халиуллина Фәүзия Зариф кызы.***

*Мин, Хәлиуллина Фәүзия Зариф кызы, 1929 нчы елда туганмын. Көне хәтеремдә түгел, хәзер инде 90га житәмдер. Сугыш башлангач, әти сугышка китте һәм шунда үлеп калды. Мин моны бик авыр кичердем.*

*7 ел Битаманда укыдым. Колхозда эшләдем, гел囂 эштә булдык, шуның өчен грамоталар, дипломлар алдым. Хезмәт стажым 24 ел. “Хезмәт ветераны” таныклыгына лаек булдым. Әни колхозда бригадир булып эшләде. Сугыш чорында безне әби карады. Ашарга күкәрин бәрәңгесе иде. Бер дә жиңел булмады тормышта. Күңел әрнегән вакытлар күп булды. Күңелле вакытта гел концертлар куя идек. Ул вакытларда авыр булса да, эшләп вакытны уздырдык.*

*Хәзерге яшь буын яман гадәтләргә ияләшмәсен, без күргәннәрне күрмәсеннәр, бәхетле булсыннар.*

